МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

18.02.2022 № 54

Казан шәһәре

Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләре үрнәкләре проектларын эшләү, аларның эчтәлегенә, алар турында иҗтимагый фикер алышуга, тикшерү кәгазьләре үрнәкләрен раслау, куллану, актуальләштерүгә карата таләпләр, шулай ук тикшерү кәгазьләрен зарури куллану очракларын раслау турында» 2021 елның 27 октябрендәге 1844 санлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазенең (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлегенең) кушымтада бирелә торган үрнәген расларга.
2. Автомобиль транспорты өлкәсендә рөхсәт бирү һәм тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты Д.Д.Мәннаповка әлеге боерыкны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерык 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Х.Садыйковка йөкләргә.

Министр Ф.М. Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
18.02.2022 № 54 боерыгы
белән расланды

Үрнәк

QR-код

Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге)

Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында кулланыла торган әлеге тикшерү кәгазе (аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) (алга таба – тикшерү кәгазе) Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга (алга таба – тикшерүдә тотыла торган затлар) карата үткәрелә торган күчмә тикшерү барышында зарури тәртиптә кулланыла.

Күчмә тикшерүнең асылы Министрлык тарафыннан расланган тикшерү кәгазе үрнәгендә күрсәтелгән зарури таләпләр белән чикләнә.

1. Контрольлек (күзәтчелек) органының исеме – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

2. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренең атамасы – җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсен төбәк дәүләт контроле.

3. Контрольлек (күзәтчелек) чарасының төре___________________________

4. Тикшерү битен тутыру көне ________________________________________

5. Үзенә карата контрольлек (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты _______________________________________

6. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның атамасы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ____________
________________________________________________________________________

7. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның яки шәхси эшкуарның ИНН һәм (яки) ОГРН ________________________________________________

8. Тикшерүдә тотылучы затлар булып торган юридик затның юридик адресы яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы ____________________________________

9. Тикшерү кәгазен тутырып контрольлек (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары) ________________________________________________________________

10. Министрның (министр урынбасарының) контрольлек (күзәтчелек) чарасын уздыру турындагы боерыгының белешмәләре ____________________________

11. Контрольлек (күзәтчелек) чарасының исәпкә алу саны ________________

12. Тикшерү (күзәтчелек) чарасын үткәрүгә вәкаләтле һәм тикшерү кәгазе тутыручы Министрлыкның вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары ___________________________________________________________________

13. Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдырган тикшерү сораулары исемлеге:

| т/с | Зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар | Норматив хокукый актларның белешмәләре | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | кулланып булмый | |
| 1. Җиңел таксига карата белдерелә торган таләпләр | | | | | | |
| 1.1. | Транспорт чараларында кузовның ян-як өслекләрен шахмат тәртибендә урнашкан капма-каршы төстәге шакмаклар күренешеннән гыйбарәт төсле график схема белән тәэмин итү таләбе үтәләме? | «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 69-ФЗ санлы федераль закон) 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы «б» пунктчасы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 1 октябрендәге 1586 санлы карары белән расланган Автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртү һәм | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | багаж ташу кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 90 пункты | | | | |
| 1.2. | Җиңел такси кузовының төсе кузовның сары яки ак төсле төсләр рәтенә туры килү-килмәү таләбе үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы «в» пунктчасы; «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты | | | | |
| 1.3. | Җиңел таксиның түбәсен кызгылт сары төстәге тану фонаре белән җиһазландыру таләбе үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы «г» пунктчасы; Кагыйдәләрнең 89 пункты | | | | |
| 1.4. | Пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен бирелгән җиңел таксидан файдаланган өчен түләү җиңел таксиның хакыйкый узган юл озынлыгына һәм аннан хакыйкый файдалану | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктындагы «д» пунктчасы; Кагыйдәләрнең 85 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | вакытына бәйсез рәвештә (билгеле бер дәрәҗәдә теркәлгән түләү рәвешендә) яисә җиңел такси белән алып баруның хакыйкый аралыгына һәм (яки) файдалануның хакыйкый вакытына бәйле рәвештә билгеләнгән тарифлардан чыгып билгеләнгән очракта, җиңел таксида таксометр булуы турындагы таләп үтәләме? | | | | | |
| 1.5. | Файдалану өчен транспорт чарасын биреп торучы зат тарафыннан җиңел таксиның алгы панелендә, йөртүчедән уң якта түбәндәге мәгълүматны урнаштыру таләбе үтәләме: а) файдалану өчен транспорт биреп торучы затның тулы яки кыскартылган атамасы, адресы һәм телефон | Кагыйдәләрнең 91 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | номерлары, файдалану өчен транспорт биреп торучы затка җиңел такси белән ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән рөхсәтнең саны, әлеге рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты, әлеге рөхсәтне биргән органның атамасы;<br>б) җиңел таксидан файдаланган өчен тарифлар | | | | | |
| 2. Җиңел таксида йөртүчегә карата белдерелә торган таләпләр | | | | | | |
| 2.1. | Җиңел таксида йөртүченең гомуми машина йөртү стажы кимендә өч ел булуы турындагы таләп үтәләме? | 9 статьясының 16 өлешендәге 2 пункты 69-ФЗ санлы федераль закон | | | | |
| 3. Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка яисә шәхси эшкуарга карата белдерелә торган таләпләр | | | | | | |
| 3.1. | Җиңел таксига техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау таләпләре үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктының «а» пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2. | Линиягә чыгар алдыннан җиңел таксиның техник торышын тикшереп тору таләбе үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктының «б» пунктчасы | | | | |
| 3.3. | Җиңел такси йөртүчеләрнең рейс алдыннан медицина тикшерүе узуын тәэмин итү таләбе үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктындагы «в» пунктчасы | | | | |
| 3.4. | Файдалану өчен транспорт биреп торучы затның транспорт чарасын яллаучы затка, шул исәптән электрон документ рәвешендә, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча тәҗрибә уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ санлы федераль законның 14 статьясы нигезендә булдырылган, җиңел таксидан файдаланган өчен түләүне раслый торган касса чегы яки | Кагыйдәләрнең 82 пунктындагы «г» пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | чек бирү йөкләмәсе үтәләме? | | | | | |
| 4. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлегенә карата таләпләр | | | | | | |
| 4.1. | Министрлыкта яисә Россия Федерациясе субъектының Татарстан Республикасы белән рөхсәтләрнең гамәлдә булуын үзара тану турында килешү төзелгән вәкаләтле органында җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга рөхсәт алган зат тарафыннан җиңел такси белән пассажирларны йөртү һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру шарты үтәләме? | 69-ФЗ санлы федераль законның 9 статьясындагы 1.4 өлеше | | | | |
| 5. Җиңел такси белән гариплеге булган затлар исәбендәге пассажирларга хезмәт күрсәтелгәндә һәм багаж ташыганда өстәмә түләү алмыйча хезмәт күрсәтү буенча таләпләр | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Транспорт чарасына утырганда һәм аннан төшкәндә гариплеге булган затлар исәбендәге пассажирга йөртүче тарафыннан ярдәм күрсәтү таләбе үтәләме? | «Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 259-ФЗ санлы федераль закон) $21^{1}$ статьясының 5 өлешендәге 1 пункты | | | | |
| 5.2. | Махсус документ булган очракта, сукырларны йөртүче махсус этне алып бару турындагы таләп үтәләме? | 259-ФЗ санлы федераль законның $21^{1}$ статьясының 5 өлешендәге 2 пункты | | | | |
| 5.3. | Гариплеге булган затлар исәбендәге пассажирның кресло-коляскасын алып бару турындагы таләп үтәләме? | 259-ФЗ санлы федераль законның $21^{1}$ статьясының 5 өлешендәге 3 пункты | | | | |
| 5.4. | Транспорт чарасын эре хәрефләр белән язылган язулар, зур хәрефләр, шул исәптән Брайльның рельефлы-нокталы хәрефләрен кулланып башкарылган, башка төрле язулы һәм | 259-ФЗ санлы федераль законның $21^{1}$ статьясының 6 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | графиклы мәгълүмат белән тәэмин итү турындагы таләп үтәлəме? | | | | | |